**МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.06. 2014 № 21-72-21

Казан ш.

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең административ регламентын раслау турында**

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә контрольлек вазыйфаларын хәл итү тәртибен раслау турында” 07.02.2014 ел, №67 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең административ регламентын (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең административ регламентының “Гомуми нигезләмәләре”ндәге 1 бүлекнең 1.9 пунктындагы “б” пунктчасының икенча абзацы нигезләмәләренең 2016 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керүен билгеләргә.
3. “Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты контрольлек-ревизия бүлекләре тарафыннан ревизияләр һәм тикшерүләр үткәрү тәртибе турында инструкцияне раслау хакында” 15.02.2008 ел, №21-72-12 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Бу боерыкны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәтергә.
5. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – министрлыкның Казначылык департаменты директоры М.Д.Фәйзрахмановка йөкләргә.

**Министр** **Р.Р.Гайзатуллин**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының
06.06.2014 ел, №21-72-21 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең бу административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан дәүләт вазыйфасын үтәүдә административ процедураларның һәм административ гамәлләрнең срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

1.2 Дәүләт вазыйфасы атамасы – финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү (алга таба – дәүләт вазыйфасы).

1.3. Министрлык финанс-бюджет-өлкәсендә контрольлек эшчәнлеген хәл иткәндә башкара:

а) бюджетта хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә эчке дәүләт финанс контрольлеге вәкаләтләрен;

б) “Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында2 5 апрель, 2013 ел, №44-ФЗ Федераль законның ( алга таба – контракт системасы турында Федераль закон) 99 статьясындагы 8 өлешендә күздә тотылган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга карата эчке дәүләт финанс контрольлеген;

в) законда күздә тотылган очракларда – җирле бюджетлар үтәлешенә контролmлекне.

Министрлык дәүләт вазыйфасын башкарганда, үтәлүенең законлылылыгын, учет һәм хисабының дөреслеген билгеләү максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы бюджетын үтәү нәтиҗәләре буенча контрольлекне хәл итә.

1.4. Контрольлек эшчәнлеге планлы һәм планнан тыш контрольлеккә бүленә һәм планлы, планнан тыш тикшерүләр үткәрү, шулай ук бюджетта хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә фәкать эчке дәүләт финанс контрольлеге вәкаләтләре кысаларында планлы һәм планнан тыш ревизияләр һәм тикшерүләр (алга таба – контрольлек чаралары) үткәрү юлы белән хәл ителә. Тикшерүләр күчмә һәм камераль тикшерүләргә, шулай ук күчмә һәм (яки) камераль тикшерүләр кысаларында үткәрелә торган каршы тикшерүләргә (встречные проверки) бүленә.

1.5. Дәүләт вазыйфасы түбәндәге затларга (алга таба – контрольлек объектлары) карата хәл ителә:

а) Татарстан Республикасы бюджет средстволарын баш бүлүчеләр (бүлүчеләр, алучылар), Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары (администраторлар), Татарстан Республикасы бюджет дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлар);

б) финанс органнары (баш бүлүчеләр (бүлүчеләр) һәм үзләренә бюджетара трансфертлар бирелгән бюджет средстволарын алучылар), үзләренә Татарстан Республикасы бюджетыннын бирелгән бюджет кредитлары һәм бюджетара транфертлар бирү максатларын һәм шартларын үтәү ягыннан;

в) гамәлдәге закон нигезендә, дәүләт (муниципаль) учреждениеләр;

г) гамәлдәге закон нигезендә, дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр;

д) устав (җыелма) капиталларында халык-хокукый оешмалары катнашында хуҗалык итүче ширкәтләр һәм җәмгыятьләр, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр өлеше (кертеме) белән коммерция оешмалары;

е) юридик затлар (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән, дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, устав (җыелма) капиталларында халык-хокукый оешмалары катнашында хуҗалык итүче ширкәтләр һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр өлеше (кертеме) белән коммерция оешмаларыннан тыш), хосусый эшмәкәрләр, физик затлар – Татарстан Республикасы бюджетыннан средстволар бирү турында килешүләр (шартнамәләр), Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен бирү турында килешүләр (шартнамәләр) шартларын үтәү ягыннан;

ж) Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүенең территориаль фонды идарәсе органнары;

з) мәҗбүри медицина иминиятләштерүен финанс белән тәэмин итү турында килешүләр буенча Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүенең территориаль фонды бюджетыннан средстволар алучы юридик затлар;

и) бюджет средстволары белән аерым операцияләрне хәл итүче кредит оешмалары – үзләренең Татарстан Республикасы бюджетыннан средстволар бирү турында килешүләр (шартнамәләр) шартларын үтәүләре ягыннан;

к) дәүләт заказчылары, контракт хезмәтләре, контракт идарәчеләре, сатып алуларны хәл итү буенча комиссияләр, Контракт системасы турында Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга юнәлдерелгән гамәлләр кылучы вәкаләтле органнар, вәкаләтле учреждениеләр, махсуслашкан оешмалар, электрон мәйданчыклар операторлары.

1.6. Дәүләт вазыйфасын Министрлык башкара.

Министрлыкның дәүләт вазыйфасын үтәүгә җаваплы структур подразделениесе – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты (алга таба – Департамент). Дәүләт вазыйфасын турыдан-туры үтәүчеләр булып Департаментның оператив контрольлек бүлеге һәм Департаментның төбәк контрольлек бүлеге, Департаментның территориаль бүлекләренең районара контрольлек-ревизия бүлекчәләре (алга таба – Бүлек, Бүлекләр) тора.

Дәүләт вазыйфасы контрольлек чарасын билгеләү турында Татарстан Республикасы финанс министры (алга таба – Министр) боерыгы нигезендә вәкаләт бирелгән Министрлыкның дәүләти гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – вазыйфаи затлар) тарафыннан турыдан-туры башкарыла. Ике яки аннан күбрәк

вазыйфаи затлар билгеләнгәндә, тикшерү (ревизия) төркеме оештырыла һәм аның җитәкчесе билгеләнә.

1.7. Дәүләт вазыйфасын үтәүгә вәкаләтле Департаментның территориаль бүлекләренең районара контрольлек-ревизия бүлекчәләре исемлеге бу Регламентка №1 кушымтада китерелгән.

1.8. Дәүләт вазыйфасын үтәү түбәндәге законнар һәм норматив-хокукый актлар нигезендә җайга салына:

– Россия Федерациясе Бюджет кодексы (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 1998, №31, 3823);

– Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2002, №1, 1 ст.);

– "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 5 апрель, 2013 ел, №44–ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2013, №14, 1652 ст., №27, 3480 ст; "Российская газета", 2013, 30 декабрь);

– Татарстан Республикасы Бюджет кодексы (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, №4–5);

– "Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы мәсьәләләре" 06.07.2005 ел, №323 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 27.07.2005, _28, 0652 ст.);

–"Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан финанс–бюджет өлкәсендә контрольлек вәкаләтләрен хәл итү тәртибен раслау турында" 07.02.2014 ел, №67 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 21.02.2014, №14, 0411 ст.);

– "Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты турында нигезләмәне раслау хакында" 04.07.2006, №21-17-77;

– "Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты территориаль бүлекләре турында нигезләмәне раслау хакында" 16.06.2009, №21-17-46 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы;

– "Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә һәм административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген һәм процессуаль документларның үрнәк формаларын раслау турында" 03.08.2009, _21-75-86 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 28.10.2009,№40, 1712 ст.).

1.9. Финанс-бюджет өлкәсендә тикшерү предметы булып контрольлек объектлары тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү тора:

а) бюджетта хокукый мөнәсәбәтләре җайга салучы, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджет средстволарын һәм Татарстан Республикасы мәҗбүри медицина иминиятләштерүенең территориаль фонды бюджетын баш бүлүчеләрнең (бүлүчеләрнең) һәм бюджет средстволары алучыларның, Татарстан Республикасы

бюджеты керемнәребаш администраторларының (администраторлар), Татарстан Республикасы бюджет дефицитын финанслау чыганаклары баш администраторларының (администраторлар) бюджет вәкаләтләрен үтәүдә хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы Россия Федерациясе бюджет законнары һәм башка норматив-хокукый актлар;

б) түбәндәгеләргә карата, Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында законнарның һәм башка норматив-хокукый актларның үтәлүе:

контракт системасы турында Федераль законның 18 статьясында күздә тотылган сатып алуларның нигезләнешенә һәм сатып алуларның нигезле булуына карата таләпләрне үтәү;

контракт системасы турында Федераль законда күздә тотылган сатып алулар өлкәсендә нормалау кагыйдәләрен үтәү;

план-графикка кертелгән бердәнбер товар җибәрүче (подрядчы, эш башкаручы) белән төзелә торган контрактның башлангыч (максималь) бәясен, контракт бәясен нигезләү;

товар җибәрүче (подрядчы, эш башкаручы) контракт шартларын бозган очракта заказчы тарафыннан җаваплылык чараларын куллану һәм башка гамәлләр кылу;

җибәрелгән товарның, башкарылган эшнең (аның нәтиҗәсе) яки күрсәтелгән хезмәтнең контракт шартларына туры килүе;

учет документларында җибәрелгән товарны, башкарылган эшне (аның нәтиҗәсе) яки күрсәтелгән хезмәтне үз вакытында, тулы һәм дөрес чагылдыру;

сатып алуга бәйле чыгымнарга карата Татарстан Республикасы бюджетын һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетын төзүнең һәм үтәүнең законлылыгын, мондый чыгымнар учеты һәм хисабының (алга таба – мәҗбүри таләпләр) дөреслеген билгеләү максатыннан чыгып, җибәрелгән товардан, башкарылган эштән (аның нәтиҗәсе) яки күрсәтелгән хезмәттән файдалануның сатып алу максатына туры килүе.

1.10. Министрлыкның вазыйфаи затларының финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итүдәге хокуклары һәм бурычлары

1.10.1. Бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән Министрлыкның вазыйфаи затлары хокуклы:

а) язмача нигезле запрос буенча контрольлек чаралары үткәрү өчен кирәкле булган язмача яки телдән мәгълүмат, документлар һәм материаллар, аңлатмалар соратып алуга;

б) күчмә тикшерүләр (ревизияләр) үткәрелгәндә хезмәт таныклыкларын һәм күчмә тикшерү үткәрү турында Министрның боерыгы күчермәсен күрсәтеп, үзләренә карата тикшерү үткәрелә торган затлар били торган бүлмәләргә һәм территориягә керүгә, җибәрелгән товарларны, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр нәтиҗәләрен күрсәтүне таләп итүгә;

в) контрольлек чаралары үткәрү өчен кирәкле экспертизалар үткәрүгә һәм (яки) мондый экспертизалар үткәрү өчен бәйсез экспертлар җәлеп итүгә;

г) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында күздә тоылган очракларда – ачыкланган бозуларны юкка чыгару турында танытмалар, күрсәтмәләр бирүгә;

д) Россия Федерациясе бюджет законында күздә тотылган очракларда һәм тәртиптә бюджет мәҗбүри чараларын куллану турында карарлар кабул итүгә;

е) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә, административ хокук бозулар турында эшләрне тикшерүгә;

ж) Россия Федераңиясе бюджет законын һәм бюджетта хокукый мөнәсәбәләрне җайга салучы башка норматив-хокукый актларны бозу сәбәпле Татарстан Республикасына китерелгән зыянны каплау турында дәгъва гаризалары белән судка мөрәҗәгать итүгә.

1.10.2. Бу Регламентның 2.5 пунктында күздә тотылган Министрлыкның вазыйфаи затлары бурычлы:

а) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә бирелгән билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмый калу вәкаләтләрен үз вакытында һәм тулысынча үтәү;

б) билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә норматив-хокукый актлар таләпләрен үтәү;

в) Министр боерыгы нигезендә контрольлек чаралары үткәрү;

г) контрольлек объекты җитәкчесен яки вәкаләтле вазыйфаи затын (алга таба – контрольлек объекты вәкиле) күчмә тикшерү (ревизия) үткәрүгә боерык күчермәсе, тикшерү (ревизия) үткәрүне туктатып тору, яңарты һәм срогын озайту турында боерык, тикшерү (ревизия) төркеменең составын үзгәртү, шулай ук контрольлек чаралары нәтиҗәләре (актлар һәм бәяләмәләр) белән таныштыру;

д) җинаять составы билгеләре булган гамәл кылу (гамәл кылмау) факты ачыкланганда, мондый факт турында мөгълүматларны һәм (яки) документларны һәм мондый фактны дәлилләүче башка материалларны хокук саклау органнарына җибәрү.

1.11. Үзләренә карата контрольлек чаралары үткәрелә торган затларның хокуклары һәм бурычлары

1.11.1. Контрольлек объектларының вазыйфаи затлары, хосусый эшмәкәрләр һәм физик затлар хокуклы:

а) контрольлек чараларын турыдан-туры карап торуга, контрольлек чаралары предметына керүче мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирүгә;

б) Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр (ревизияләр), тикшеренүләр бәяләмәләре белән танышу,

в) бу Регламент һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары нигезендә билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның һәм аның вазыйфаи затларының карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерү;

г) Министрлыкның һәм аның вазыйфаи затларының хокукка каршы килә торган гамәлләре белән китерелгән чынбарлыктагы зыянны Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә каплауга.

1.11.2. Контрольлек объектларының вазыйфаи затлары, хосусый эшмәкәрләр һәм физик затлар бурычлы:

а) җитәкченең, башка вазыйфаи затларның яки хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча чаралар оештыру һәм үткәрүгә җаваплы затның вәкаләтле вәкиленең булуын тәэмин итү;

б) контрольлек чаралары үткәрү өчен кирәкле мәгълүматны, документларны һәм материалларны үз вакытында һәм тулы күләмендә тапшыру;

в) Министрлыкның вазыйфаи затларына телдән һәм язмача аңлатмалар бирү;

г) тикшерү (ревизия) төркеме составына кергән вазыйфаи затларга, читтән җәлеп ителгән белгечләргә һәм экспертларга кирәкле оештыру һәм техник ярдәм күрсәтү, шул исәптән аларны документлар һәм материалларның сакланылышын тәэмин итәрдәй кирәкле хезмәт бүлмәләре белән тәэмин итү;

д) тикшерү (ревизия) составына кергән вазыйфаи затларна бүлмәләр һәм территорияләргә комачаулыкларсыз керүне тәэмин итү, товарлар, башкарылган эшләр, хезмәтләр нәтиҗәләрен күрсәтү;

е) тикшерү (ревизия) составына кергән вазыйфаи затларның башка законлы таләпләрен үтәү, шулай ук әлеге затларга хезмәттәге бурычларын үтәүдә законлы эшчәнлекләренә комачаулык тудырмау;

ж) танытмалар, күрсәтмәләр таләпләрен үз вакытында һәм тулы күләмендә үтәү;

з) бухгалтерия (бюджет) учеты һәм законнарда, башка норматив-хокукый актларда күздә тотылган бүтән документлар мәгълүматларының сакланылышын тәэмин итү;

и) контрольлек чаралары кысаларында җәлеп ителгән белгечләрнең һәм экспертларның бүлмәләргә, территориягә, шулай ук тикшеренүләр, экспертизалар объектларына керүен тәэмин итү;

к) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында күздә тотылган башка бурычларны үтәү.

1.12. Дәүләт вазыйфасын үтәү нәтиҗәсенең тасвирламасы:

1.12.1. Дәүләт вазыйфасын үтәү нәтиҗәләренә керә:

1) камераль һәм күчмә тикшерүләр нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән актлар, кушымталары белән (каршы тикшерү акты, тикшеренү үткәрү нәтиҗәләре буенча әзерләнгән бәяләмә, экспертизалар (тикшеренүләр) нәтиҗәләре, контрольлек чараларын үткәрү барышында алынган фото-, видео- һәм аудиоматериаллар);

2) Министр карары нигезендә камераль һәм күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча кулланыла торган мәҗбүриләү чаралары.

а)карап тикшерү өчен мәҗбүри булган Россия Федерациясе бюджет законын һәм бюджетта хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы башка норматив-хокукый актларны бозулар (ачыкланган) турында мәгълүматтан һәм аларны юкка чыгару чараларын күрү, шулай ук мондый бозулар сәбәпләрен һәм шартларын юкка чыгару турындагы таләпләрдән торган танытмалар;

б) Россия Федерациясе бюджет законын һәм бюджетта хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы башка норматив-хокукый актларны, яки сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законын һәм норматив-хокукый актларны бозуларны юкка чыгару турында һәм (яки) мондый бозулар белән китерелгән зыянны каплау турында таләпләрдән торган күрсәтмәләр;

в) Министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә хәл ителә торган бюджет мәҗбүриләү чаралары.

3) тикшеренү үткәрү нәтиҗәләре буенча әзерләнгән бәяләмәне карап тикшерү йомгаклары нигезендә Министр карары белән билгеләнгән күчмә тикшерү (ревизия), шулай ук, контрольлек объекты тарафыннан язмача каршы килүләр, күчмә тикшерү (ревизия) нәтиҗәләре буенча ясалган йомгакларга йогынты ясый торган, тикшерелә торган чорга кергән өстәмә мәгълүматларны, документлар һәм

материалларны кушымта итеп тапшырганда, камераль яки күчмә тикшерү (ревизия) нәтиҗәләре буенча планнан тыш күчмә тикшерү (ревизия);

4) тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесенең нигезле мөрәҗәгате буенча Министр тарафыннан билгеләнгән тикшеренү, каршы тикшерү;

5) Россия Федерациясе бюджет законын һәм бюджетта хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы башка норматив-хокукый актларны бозу сәбәпле Татарстан Республикасына китерелгән зыянны каплау турында күрсәтмә үтәлмәгән очракта – вазыйфаи затлары бозуга юл куйган контрольлек объекты тарафыннан Татарстан Республикасына китерелгән зыянны каплау турында Министрлык судка җибәргән дәгъва гаризасы;

6) администртаив хокук бозу турында беркетмә;

7) Россия Федерациясе законында күздә тотылган тәртиптә карап тикшерү өчен, ачыкланган очракта, бозу билгеләре турында сөйләүче хәлләр һәм фактлардан торып, мондый бозуларны карап тикшерүгә компетентлы башка дәүләт органына (вазыйфаи зат) җибәрелгән материаллар.

1.12.2. Контрольлек чараларында катнашучы вазыйфаи затлар контрольлек объекты тарафыннан танытмалар һәм күрсәтмәләрнең үтәлешенә контрольлек итә. Китерелгән зыянны каплау турында танытма һәм (яки) күрсәтмә үтәлмәгән очракта, Министрлык, Россия Федерациясе законы нигезендә, мондый танытманы һәм (яки) күрсәтмәне үтәмәгән затка карата җаваплылык чаралары күрә.

1.12.3. Бу Регламентта күздә тотылган танытмалар һәм күрсәтмәләр һәм башка документлар формалары һәм аларны рәсмиләштерүгә карата таләпләр Министрлык тарафыннан билгеләнә.

**2. Дәүләт вазыйфасын үтәү тәртибенә карата таләпләр**

2.1. Дәүләт вазыйфасын үтәү турында мәгълүмат җиткерү тәртибе

2.1.1. Министрлыкның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Казан ш., Пушкин ур., 37 й.

2.1.2. Дәүләт вазыйфасын үтәү мәсьәләләре буенча документлар һәм гаризалар кабул итү урыны: 420111, Татарстан Республикасы, Казан ш., Пушкин ур., 37 й. Дәүләт вазыйфасын үтәү мәсьәләләре буенча документлар һәм гаризалар кабул итү шулай ук Департамент һәм, бу Регламентка №1 кушымтада китерелгән адреслар буенча, аның территориаль бүлекләре тарафыннан хәл ителә.

2.1.3. Министрлыкның, Департаментның һәм аның территориаль бүлекләренең эш графигы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00-18.00; җомга – 9.00-16.45. Төшке аш вакыты: 12.00-12.45. Бәйрәм алды көннәрендә Министрлыкның, Департаментның, аның территориаль бүлекләренең эш вакыты озынлыгы бер сәгатькә кими.

2.1.4. Дәүләт вазыйфасын үтәү мәсьәләләре буенча кызыксынулы затлар тарафыннан мәгълүмат алу өчен Министрлыкның, Департаментның телефоннары: (843) 264-79-91, 291-96-21.

2.1.5. Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты (алга таба – рәсми сайт) адресы: www.minfin.tatar.ru. Министрлыкка, Департаментка электрон мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен электрон почта адресы: minfin@tatar.ru. Департаментның территориаль бүлекләренең электрон почта адреслары бу Регламентка №1 кушымтада күрсәтелгән.

2.1.6. Кызыксынулы затларга дәүләт вазыйфасын үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүматлар, дәүләт вазыйфасын үтәүнең барышы турында мәгълүматлар тапшырыла:

– телдән(яки шәхсән телефон аша) мөрәҗәгать буенча;

– язмача мөрәҗәгать буенча;

– электрон почта аша;

– Министрлыкның рәсми сайтыннан, "Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы" Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан (http://uslugi@tatar.ru) (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) файдаланып, электрон рәвештә җибәрү юлы белән;

– Департамент бүлмәсендәге мәгълүмати стенд аша.

Телдән мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгать ителгәннән соң кичекмәстән бирелә, язмача мөрәҗәгатькә һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгатькә җавап почта аша күрсәтелгән почта адресына яки электрон адреска әлеге мөрәҗәгать теркәүгә алынганнан соң утыз көннән дә артмаган срокта җибәрелә, һәм анда куелган сорауларга җаваплар, эш башкаручының фамилиясе, инициаллары һәм телефон номеры булырга тиеш. Җавапка Министр (Министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары) кул куя.

Телефоннан шалтыратуны кабул иткән Министрлыкның вазыйфаи заты куелган сорауларга мөстәкыйль җавап бирә алмаган очракта, телефоннан сөйләшү башка вазыйфаи затка тоташтырылырга (күчерелергә) тиеш яки мөрәҗәгать итүчегә кирәкле мәгълүмат алып булу мөмкинлеге биргән телефон номеры җиткерелергә тиеш.

2.1.7. Белешмәләр алу телефоны аша дәүләт вазыйфасын үтәү мәсьәләләренә кагылышлы белешмәләр, дәүләт вазыйфасын үтәүнең барышы турында мәгълүматлар бирелгәндә, түбәндәге мәгълүматлар да бирелә;

а) делопроизводство системасында теркәлгән хатларның керү номерлары;

б) җавапның җибәрелүе.

Министрлыкның эшчәнлеге турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайты, мәгълүмати агентлыклар, матбугат, радио һәм телевидение аша җиткерелә.

2.1.8. Кызыксынулы затларга Министрлыкның рәсми сайтында, Департаментның мәгълүмати стендларында түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:

а) урнашу урыны, элемтәгә керү өчен телефоннары, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтлары, Департаментның территориаль бүлекләренең электрон почта адреслары турында мәгълүматлар;

б) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарының дәүләт вазыйфасын үтәү тәртибенә кагылышлы төп нигезләмәләре турында мәгълүмат;

в) кушымталары белән, бу Регламент;

г) дәүләт вазыйфасын үтәүче вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерү тәртибе.

2.1.9. Бу Регламент, Татарстан Республикасы Премьер-министры белән килешенеп, Министр тарафыннан расланган контрольлек чараларының еллык планы (алга таба – контрольлек чаралары планы) Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

2.2. Финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү буенча чаралар үткәрү өчен юридик затлардан, хосусый эшмәкәрләрдән, физик затлардан түләү алырга ярамау

Финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү буенча чаралар үткәрү өчен юридик затлардан, хосусый эшмәкәрләрдән, физик затлардан түләү алынмый, шул исәптән, тикшерүгә җәлеп иткән очракта, экспертлар һәм эксперт оешмалары хезмәтләре өчен дә.

2.3. Дәүләт вазыйфасын үтәү срогы

2.3.1. Контрольлек чаралары үткәрүнең түбәндәге максималь сроклары билгеләнгән:

күчмә тикшерү, ревизия үткәрү – күп дигәндә утыз эш көне;

камераль тикшерү үткәрү– контрольлек объектыннан Министрлык запросы буенча тапшырылган мәгълүмат, документлар һәм материаллар алынганнан соң күп дигәндә егерме эш көне;

тикшеренү үткәрү (камераль һәм күчмә тикшерүләр кысаларында үткәрелгән тикшеренүдән тыш) – күчмә тикшерүләр (ревизияләр) өчен билгеләнгән срокларда;

каршы тикшерү үткәрү – күп дигәндә егерме эш көне эчендә.

Министр, тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесенең нигезле мөрәҗәгате буенча, күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү срогын күп дигәндә ун эш көненә озайтырга мөмкин.

2.3.2. Бер контрольлек объектына һәм бер контрольлек чарасы темасына карата планлы контрольлек чаралары күп дигәндә елына бер тапкыр үткәрелергә мөмкин.

2.4. Тикшерүләр үткәрүгә нигезләр

2.4.1. Планлы контрольлек чаралары, Татарстан Республикасы Премьер-министры белән килештереп, Министр тарафыннан plандагы елдан алдан килүче елның 25 декабреннән дә соңга калмыйча раслана торган контрольлек чаралары планы нигезендә хәл ителә.

Министрлыкның контрольлек чаралары планын төзү түбәндәге шартларны үтәү нигезендә хәл ителә:

а) Министрлыкның контрольлек чаралары планы параметрларының бюджет системасының тиешле балансын һәм тотрыклылыгын тәэмин итүгә, дәүләт финанслары белән идарә итүнең сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программалары күрсәткечләренә туры килүе;

б) контрольлек чараларында катнашучы структур подразделениеләргә төшә торган нагрузканы тигезләүне тәэмин итү;

в) алдагы елларда хәл ителгән планнан тыш контрольлек чаралары турында мәгълүматлар нигезендә билгеләнелә торган планнан тыш контрольлек чараларын үтәү өчен вакыт бирү.

Контрольлек чараларын сайлап алу түбәндәге критерийлардан чыгып хәл ителә:

а) үзләренә карата финанс контрольлеген үткәрү һәм (яки) бюджет чыгымнары күләмнәрен җибәрү күздә тотылган контрольлек объектлары тарафыннан хәл ителә торган чараларның мөһимлеге һәм әһәмиятлелеге;

б) бюджет средстволарының баш администраторлары тарафыннан эчке финанс контрольлеген һәм эчке финанс аудитын хәл итүне анализлау нәтиҗәсендә алынган

контрольлек объектына карата эчке финанс контрольлеге һәм аудиты торышын бәяләү;

в) дәүләт финанс контрольлеге органы тарафыннан шундый ук контрольлек чарасы үткәрелгәннән соң узган чор озынлыгы (әлеге чор өч елдан артып киткән очракта әлеге критерий иң зур өстенлек ала);

г) дәүләт финанс контрольлеге органнарыннан, җирле хакимиятләрдән, Татарстан Республикасы бюджет чыгымнарының баш администраторларыннан алынган, шулай ук сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмати система мәгълүматларын анализлау нәтиҗәләре буенча ачыкланган бозу билгеләренең булуы турында мөгълүмат.

Министрлыкның контрольлек чаралары планын булдыру Бүлекләр начальниклары тарафыннан, контрольлек чараларының кабатлануын булдырмау максатыннан чыгып, башка дәүләт органнары планлаштыра (үткәрә) торган шундый ук контрольлек чаралары турында мәгълүматны исәпкә алып, чираттагы финанс елы башланырга кимендә кырык биш көн кала хәл ителә.

2.4.2. Планнан тыш контрольлек чаралары, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, хокук саклау органнары мөрәҗәгатьләре (поручениеләр), депутат запрослары, башка дәүләт органнары, гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләре алынуга бәйле рәвештә, шулай ук Россия Федерациясе законын бозу билгеләре ачыкланган очракта, Министрның карары нигезендә хәл ителә.

Планнан тыш контрольлек чаралары билгеләү турында карар кабул итү тәртибе бу Регламент нигезендә билгеләнә.

2.5. Финанс–бюджет өлкәсендә турыдан-туры контрольлекне хәл итүче вазыйфаи затлар

Финанс–бюджет өлкәсендә турыдан-туры контрольлекне хәл итүче вазыйфаи затлар булып тора:

а) Министр:

б) үзенең компетенциясенә финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү мәсьәләләре кергән Министрның беренче урынбасары (алга таба – Министрның әеренче урынбасары);

в) контрольлек чараларын оештыруга җаваплы Министр урынбасарлары (алга таба – Министр урынбасарлары);

г) Министр боерыгы нигезендә контрольлек чараларын үткәрүдә катнашуга вәкаләтле булып, тикшерү (ревизия) төркеме составына керә торган һәм җаваплы эш башкаручылар булып торган Министрлыкныҗ башка дәүләти гражданлык хезмәте хезмәткәрләре.

2.6. Тикшерү үткәргәндә Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының җаваплылыгы

2.6.1. Министрлык, бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлары тикшерү үткәргәндә вазыйфаларын, хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәгән, хокукка каршы гамәлләр кылган (гамәл кылмау) өчен Россия Федерациясе законы нигезендә җавап бирә.

2.6.2. Россия Федерациясе законын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында Министрлык хокуклары һәм (яки) законлы

мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, хосусый эшмәкәргә, физик затка мондый чаралар күрелгәннән соң ун көн эчендә язмача хәбәр итәргә тиеш.

**3. Юридик затларга, хосусый эшмәкәрләргә һәм физик затларга карата куела торган мәҗбүри таләпләр**

Үтәлеше контрольдә тотылып, юридик затларга, хосусый эшмәкәрләргә һәм физик затларга карата куела торган мәҗбүри таләпләр исемлеге, тиешле таләпләрне билгели торган норматив-хокукый актларны күрсәтеп, 1 нче таблицада китерелгән

1 нче таблица. Юридик затларга, хосусый эшмәкәрләргә һәм физик затларга карата куела торган мәҗбүри таләпләр исемлеге

| Мәҗбүри таләп формулировкасы | Мәҗбүри таләпне билгеләүче норматив-хокукый акт | Оридик затлар, хосусый Юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр тарафыннан |
|---|---|---|
| **1. Контрольлек объектлары эшчәнлегенең гамәлгә кую документларына туры килү ягыннан РФ законнарын** | **РФ Бюджет кодексының 269.2 статьясы; ТР Бюджет кодексының 101статьясындагы п.1 ; “Юридик затларны һәм хосусый эшмәкәрләрне дәүләт теркәвенә алу турында” 08.08.2001. № 129-ФЗ Федераль** | **Хокукны билгеләү документлары (устав, таныклыклар һ.б.), шәхесне раслаучы документлар** |
| **2. Бюджет средстволарын бирү нигезләренең РФ законында билгеләнгән таләпләргә** | **РФ Бюджетного кодексының 6, 69, 69.1, 74.1, 78, 78.1, 78.2, 79 80, 81, 83 статьялары** | **Дәүләти (муниципаль) контрактлар, бюджет средстволарын бирүгә башка килешүләр, бүтән норматив-хокукый актлар, шартнамәләр** |
| **3. Бюджет средстволарыннан максатчан файдалану турында таләпләрне үтәү** | **РФ Бюджет кодексының 38,158 статьялары** | **Дәүләти (муниципаль) контрактлар, бюджет средстволарын бирүгә башка килешүләр, бүтән норматив-хокукый актлар, шартнамәләр, бюжет средстволарын тотуны раслаучы** |

| | | |
|---|---|---|
| **4. ТР бюджеты средстволары хисабына түләнелергә тиешле акчалата бурычның килеп чыгуын раслаучы** | **“Бухгалтерия учеты турында” 06.12.2011, № 402-ФЗ Федераль законның 9, 10 статьялары “Оешмаларның бухгалтерия учеты формалары турында” 02.07.2010, № 66н Россия Финанс министрлыгы боерыгы ; “Оешмаларның бухгалтерия учеты” бухгалтерия учеты** | **Беренчел учет документлары, шул исәптән банк һәм касса документлары, бухгалтерия хисабы учеты һәм формасы регистрлары** |

**4.Тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, хосусый эшмәкәр һәм физик зат тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге**

Тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, хосусый эшмәкәр һәм физик зат тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица. Тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларын ирешү өчен юридик зат, хосусый эшмәкәр һәм физик зат тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| **№** | **Тикшерү үткәрү өчен тапшырыла торган документ** | **Документның формасын билгеләүче норматив-хокукый акт** |
|---|---|---|
| **1.** | **Гамәлгә кую документларының һәм хокукны билгеләүче башка документларның, шәхесне раслау документларының күчермәләре** | 08.07.1997 № 828 “РФ гражданины паспорты, РФ гражданины паспортының бланк үрнәге һәм паспорт тасвирламасы турында нигезләмәне раслау |
| **2.** | **Килешүләр (шартнамәләр) яки Татарстан Республикасы бюджетыннан средстволар бирүгә хокукый нигез булып торучы башка документлар** | - |
| **3.** | **Татарстан Республикасы бюжеты средстволары Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителгән чыгымнарны раслаучы беренчел учет документлары, бухгалтерия учеты** | “Бухгалтерия хисабы турында” 6 декабрь, 2011 ел,№ 402-ФЗ РФ |
| **4.** | **Бухгалтерия хисабы күчермәсе, соңгы хисап датасына салым органы билгесе белән, узган финанс елы йомгаклары буенча** | **“Оешмаларның бухгалтерия хисабы формалары турында”02.07.2010, №** |

| | | |
|---|---|---|
| **5.** | **Соңгы хисап датасына фмнанс (бухгалтерия) хисабынын дөреслеге турында аудитор бәяләмәсе** | **-** |
| **6.** | **Хезмәткәрләрнең, тикшерелә торган юридик затның һәм хосусый эшмәкәрнен аңлатма язулары** | **-** |

**5. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны башкару срокларьы, аларны башкару тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләр) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре**

Контрольлек чаралары тикшерү, ревизия, тикшеренү ысулы белән хәл ителә. Тикшерүләр (планлы, шулай ук планнан тыш) күчмә һәм камераль тикшерүләргә, шул исәптән күчмә һәм (яки) камераль тикшерүлә кысаларында үткәрелә торган каршы тикшерүләргә бүленә.

Планлы һәм планнан тыш ревизияләр һәм тикшеренүләр бюджетта хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә эчке дәүләт финанс контрольлеге буенча вәкаләтләр кысаларында гына хәл ителә.

Каршы тикшерүләр күчмә яки камераль тикшерүләр кысаларында контрольлек объекты эшчәнлегенә бәйле фактларны билгеләү һәм (яки) раслау максатында үткәрелергә мөмкин.

Камераль тикшерүләр Министрлыкның (аның структур подразделениеләре) урнашу урыны буенча үткәрелә.

Күчмә тикшерүләр, ревизияләр контрольлек объектының һәм аның аерымланган подразделениеләренең урнашу урыны буенча үткәрелә.

Тикшеренү үткәрелгәндә, контрольлек объекты эшчәнлеге өлкәсе торышына анализ ясала һәм бәя бирелә.

Дәүләт вазыйфасын үтәү кысаларында түбәндәге административ процедуралар хәл ителә:

планлы камераль тикшерү үткәрү;

планлы күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү;

тикшеренү үткәрү;

планнан тыш камераль тикшерү үткәрү;

планнан тыш күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү.

Дәүләт вазыйфасын үтәүнең блок-схемасы бу Регламентка №2, 2а кушымталарда китерелгән.

Контрольлек чарасы үткәрү туктатылып торырга мөмкин. Контрольлек чарасын үткәрүне туктатып тору турында карар, тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесенең нигезле мөрәҗәгате буенча, Министр тарафыннан кабул ителә. Контрольлек чарасын үткәрүне туктатып тору вакытында үткәрү срогы өзелеп тора.

Контрольлек чарасын үткәрүне яңартып җибәрү турында карар контрольлек чарасын үткәрүне туктатып тору сәбәпләре юкка чыгарылганнан соң хәл ителә.

Контрольлек чарасын үткәрүнетуктату (яңартып җибәрү) турында карар Министр боерыгы белән рәсмиләштерелә. Контрольлек чарасын үткәрүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында карар күчермәсе контрольлек объекты исеменә җибәрелә.

5.1. “Планнан тыш камераль тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.1.1. “Планнан тыш камераль тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлауга нигез булып тиешле контрольлек объектын контрольлек чаралары планына кертү тора. Контрольлек объектын контрольлек чаралары планына кертү бу Регламентның 2.4.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча хәл ителә.

5.1.2. Планлы камераль тикшерү, Министрлыкның (аның структур подразделениеләре) урнашу урыны буенча, бюджет (бухгалтерия) хисабы һәм Министрлык запрослары буенча тапшырылган башка документлар нигезендә, шулай ук каршы тикшерүләр үткәрү барышында алынган мәгълүматлар, документлар һәм материаллар нигезендә үткәрелә.

5.1.3. “Планлы камераль тикшерү үткәрү” административ процедурасы административ гамәлләрнең түбәндәге тәртибе нигезендә хәл ителә:

“Контрольлек чарасына җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү – планлы камераль тикшерү үткәрү;

Планлы камераль тикшерү билгеләү турында Министрлык боерыгын рәсмиләштерү;

Планлы камераль тикшерү программасын раслау;

Планлы камераль тикшерү үткәрү турында контрольлек объектына хәбәр итү;

Планлы камераль тикшерү үткәрү;

Планлы камераль тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

5.1.4. Тикшерүне үткәрүче Бүлек начальнигы контрольлек чаралары планы нигезендә контрольлек объектына планлы камераль тикшерү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затларны билгели.

Башкару срогы: планлы камераль тикшерү башланырга биш эш көне кала.

Гамәл нәтиҗәсе: Бүлек начальнигы тарафыннан планлы камераль тикшерү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү.

5.1.5. Бүлек начальнигы тарафыннан билгеләнгән белгеч, бу Регламентка №3 кушымта нигезендәге форма буенча, контрольлек объектына планлы камераль тикшерү билгеләү турында боерык проекты әзерли.

Контрольлек объектына планлы камераль тикшерү билгеләү турында боерыкта күрсәтелә:

а) контрольлек объекты атамасы;

б) соңыннан контрольдә тотылып, тикшерү чоры;

в) контрольлек чарасы темасы;

г) контрольлек чарасын үткәрүгә нигез;

д) контрольлек чарасын үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар составы, тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесен, шулай ук, контрольлек чарасын үткәрүгә җәлеп итү очрагында, белгечләр, экспертларның вазыйфалары, фамилияләре һәм инициаллары;

е) контрольлек чарасын үткәрү срогы;

ж) контрольлек чарасын үткәрү барышында өйрәнелергә тиешле төп мәсьәләләр исемлеге.

Башкару срогы:

Тикшерү үткәрүгә дүрт эш көне кала.

Гамәл нәтиҗәсе: планлы камераль тикшерү билгеләү турында боерык проекты.

5.1.6. Бүлек начальнигы тарафыннан билгеләнгән белгеч планлы камераль тикшерү программасын әзерли, программа планлы камераль тикшерү билгеләү турында Министр боерыгы белән раслана.

Тикшерү программасы түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) тикшерү темасы;

б) тикшерү объекты атамасы;

в) тикшерү барышында өйрәнелергә тиешле мәсьәләләр исемлеге.

Бүлек начальнигы тарафыннан билгеләнгән белгеч планлы камераль тикшерү билгеләү турында боерык проектын, планлы камераль тикшерү программасы белән бергә Министрга имза салуга җибәрә.

Башкару срогы: планлы камераль тикшерү үткәрү башланырга дүрт эш көне кала.

Гамәл нәтиҗәсе: планлы камераль тикшерү билгеләү турында Министр тарафыннан имзаланган боерык һәм әлеге боерык белән расланган планлы камераль тикшерү программасы.

5.1.7. Контрольлек чарасын үткәрүгә җаваплы вазыйфаи зат планлы камераль тикшерү үткәрү турында контрольлек объектына җиткерә, шулай ук тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсен почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) яки аның адресат тарафыннан алыну датасын дәлилләүче башка ысул белән (телефон элемтәсе) телефонограмма) факсимиль элемтә (факсограмма) электрон почта аша, яисә кабул итеп алу турында билге белән, кулга тапшырып, контрольлек объекты турында документлар, материаллар һәм мәгълүмат тапшыру хакында запрос җибәрә.

Башкару срогы: тикшерү башланырга өч эш көне кала.

Гамәл нәтиҗәсе: планлы камераль тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсен контрольлек объекты исеменә җибәрү.

Башкару срогы: тикшерү үткәрүне башлап җибәрергә өч эш көне кала.

Гамәл нәтиҗәсе: планлы камераль тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсен контрольлек объекты исеменә җибәрү.

5.1.8. Контрольлек чаралары үткәрү өчен кирәкле документлар, материаллар һәм мәгълүмат төп нөсхәдә яки контрольлек объектлары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәләре рәвешендә тапшырыла.

Планлы камераль тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсен контрольлек объекты исеменә юллау Министрлыкта делопроизводство алып бару кагыйдәләре нигезендә, билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

Контрольлек объекты запроста күрсәтелгән документларны электрон документлар рәвешендә тапшыруга хокуклы.

Планлы камераль тикшерү үткәрелгәндә, министрлык тарафыннан контрольлек объекты исеменә запрос җибәрү датасыннан соралган докуентларны, материаллар һәм мәгълүматны алу датасына кадәрген чор, шулай ук каршы тикшерү һәм (яки) тикшеренү үткәрү чоры планлы камераль тикшерү үткәрү срогына кертелми.

Планлы камераль тикшерү үткәрелгәндә контрольлек объектының вазыйфаи заты, хосусый эшмәкәр һәм физик зат тарафыннан документлар, материаллар һәм мәгълүмат тапшырылмаганда яки вакытында тапшырылмаганда бу Регламентка №4 кушымта нигезендәге форма буенча акт төзелә.

Башкару срогы: запроста билгеләнгән һәм контрольлек объекты тарафыннан запрос алыну датасыннан исәпләнелә торган срок нигезендә, әмма 3 эш көненнән дә кимрәк түгел.

Гамәл нәтиҗәсе: контрольлек объекты тарафыннан тапшырылган документлар, материаллар һәм мәгълүмат. Кирәк булганда, камераль тикшерү үткәрелгәндә контрольлек объекты тарафыннан мәгълүмат тапшырмау турында актны контрольлек объекты исеменә җибәрү.

5.1.9. Планлы камераль тикшерү үткәрү процессында контрольлек чаралары өчен җаваплы вазыйфаи затлар контрольлек объекты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тапшырылган документларны алдагы тикшерүләр актларын, административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерү материалларын һәм әлеге контрольлек объектына карата элегрәк үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре турында башка документларны карап тикшерә.

Контрольлек чарасы контрольлек объекты эшчәнлегенең түбәндәге юллар белән Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу һәм бюджетта хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен билгеләүгә юнәлдерелә:

а) мәгълүмат һәм документлар сорату һәм алу;

б) аңлатмалар алу;

в) тикшеренүләр һәм экспертизалар билгеләү һәм үткәрү.

Башкару срогы: контрольлек объектыннан Министрлык запросы буенча тапшырылган мәгълүмат, документлар һәм материалларны алганнан соң күп дигәндә егерме эш көне.

Гамәл нәтиҗәсе: вазыйфаи затлар тарафыннан контрольлек объекты тапшырган документларны, материал һәм мәгълүматны карап тикшерү.

Контрольлек объекты тарафыннан тапшырылган документлар, материаллар һәм мәгълүматны карап тикшергәннән соң финанс ягыннан бозу билгеләре ачыкланган очракта, контрольлек чарасы өчен җаваплы вазыйфаи затлар күчмә тикшерү үткәрүгә хокуклы. Күчмә тикшерү үткәрү турында карарны Министр кабул итә. Бу очракта планлы камераль тикшерү нәтиҗәсе “Планлы күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү” административ процедурасын үткәрүне башлау өчен нигезгә туры килергә тиеш.

Күчмә тикшерү (ревизия) бу Регламентның 5.2.2 пунктчасында китерелгән тәртиптә хәл ителә.

5.1.10. Планлы камераль тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү үткәрүче вазыйфаи зат бу Регламентка №7 кушымта нигезендәге форма буенча акт рәсмиләштерә. Актка тикшерү үткәрүче вазыйфаи зат, планлы камераль тикшерү үткәрү срогының соңгы көненнән дә соңга калмыйча, кул куя.

Планлы камераль тикшерү акты ике нөсхәдә төзелә, аларның берсе торган имзаланганнан соң өч көн эчендә (эш көннәрендә исәпләнелә) контрольлек объекты вәкиленә тапшырыла яки тапшыру турында уведомление белән почта аша заказлы хат белән яисә адресат тарафыннан алыну датасын дәлилләүче башка ысул белән җибәрелә. Планлы камераль тикшерү актының икенче нөсхәсе делога тегеп куела.

Планлы камераль тикшерү материаллары Министр тарафыннан яки аның кушуы буенча Министрның беренче урынбасары, Министр урынбасарлары

тарафыннан, актка кул куелганнан соң унбиш көнлек срокта (эш көннәрендә исәпләнелә) карап тикшерелергә тиеш.

Министр актны һәм планлы камераль тикшерүнең башка материалларын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул итә:

а) мәҗбүриләү чараларын куллану турында әлеге чараларга Россия Федерациясе законы һәм Татарстан Республикасы законы нигезендә контрольлек объектына җибәрелә торган танытмалар, күрсәтмәләр кирә, бюджет мәҗбүриләү чараларын куллану турында;

б) мәҗбүриләү чараларын куллануга нигезләрнең булмавы турында;

в) күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү турында.

Россия Федерациясе бюджет законын бозулар ачыкланган очракта министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15.1, 15.14-15.15.16 статьяларында күздә тотылган хокук бозулар составлары буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзи.

Башка дәүләт органы (вазыйфаи зат) компетенциясенә кергән бозу билгеләре турында дәлилләүче хәлләр һәм фактлар ачыкланган очракта, мондый материаллар Россия Федерациясе законы нигезендә билгеләнгән тәртиптә карап тикшерүгә җибәрелә.

Министрлык контрольлек объектына танытмалар һәм (яки) күрсәтмәләр җибәрә. Китерелгән зыянны каплау турында танытманы һәм (яки) күрсәтмәне үтәмәү очрагында Министрлык мондый танытманы һәм (яки) күрсәтмәне үтмәгән затка Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылык чаралары күрә.

Россия Федерациясе бюджет законын һәм бюджетта хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы башка норматив-хокукый актларны бозу нигезендә Татарстан Республикасына китерелгән зыянны каплау турында күрсәтмәне үтәмәү очрагында Министрлык мондый бозуга юл куйган контрольлек объекты, вазыйфаи затлар тарафыннан Татарстан Республикасына китерелгән зыянны каплау турында судка дәгъва гаризасы җибәрә һәм судта әлеге дәгъва буенча Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен яклый.

Башкару срогы:

актны төзү һәм имзалау – планлы камераль тикшерү үткәрү срогының соңгы көненнән дә соңга калмыйча;

контрольлек объектына акт тапшыру (җибәрү) – имза салынганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча;

планлы камераль тикшерү материалларын карап тикшерү һәм Министр тарафыннан карар кабул итү – актка кул куелганнан соң унбиш эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәл нәтиҗәсе: планлы камераль тикшерү актының ике нөсхәсе, шуның берсе контрольлек объекты исеменә җибәрелә, икенчесе – делога тегеп куела;

актны һәм планлы камераль тикшерү буенча башка материалларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министр тарафыннан кабул ителгән карар.

5.1.11. Контрольлек объектлары планлы камераль тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән актка, акт алынганнан соң биш эш көне эчендә, язмача рәвештә каршы килүләрне тапшыруга хокуклы. Тикшерү акты буенча контрольлек объектының язмача каршы килүләре тикшерү материаллары янына куела.

5.1.12. Камераль тикшерүләр кысаларында контрольлек объекты эшчәнлегенә бәйле фактларны билгеләү һәм (яки) раслау максатыннан чыгып, тикшеренүләр һәм (яки) каршы тикшерүләр үткәрелергә мөмкин.

Планлы камераль тикшерүләр кысаларында үткәрелә торган тикшеренү әлеге тикшерүләр өчен билгеләнгән сроклардан артмаган срокта үткәрелә. Тикшеренү бу Регламентның 5.1.4-5.1.7, 5.3.4-5.3.7 пунктчалары нигезендә хәл ителә.

Каршы тикшерүләр бу Регламент нигезендә күчмә яки камераль тикшерүләр өчен билгеләнгән тәртиптә билгеләнә һәм үткәрелә.

Каршы тикшерүләрне үткәрү срогы егерме эш көненнән артмаска тиеш.

Үзләренә карата күчмә тикшерү үткәрелә торган затлар һәм оешмалар контрольлек чарасы өчен җаваплы вазыйфаи затларның запросы (таләбе) буенча камераль тикшерү тематикасына керүче мәгълүмат, документлар һәм материаллар тапшыруга бурычлы.

Каршы тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, бу акт камераль тикшерү материаллары янына куела.

Каршы тикшерү нәтиҗәләре буенча каршы тикшерү объектына карата мәҗбүриләү чаралары кулланылмый.

5.1.13. “Планлы камераль тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе электрон рәвештә Министрлыкның рәсми сайтында теркәлә.

5.2. “Планлы күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү” административ процедурасы

5.2.1. “Планлы күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү” административ процедурасын башлауга нигез булып тиешле контрольлек объектын контрольлек чаралары планына кертү тора. Контрольлек объектын тикшерүне контрольлек чаралары планына кертү бу Регламентның 2.4.1 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча хәл ителә.

5.2.2. “Планлы күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү” административ процедурасы административ гамәлләрнең түбәндәге тәртибе нигезендә хәл ителә.

Контрольлек арасын үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү – күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү;

планлы күчмә тикшерү (ревизия) билгеләү турында боерыкны рәсмиләштерү;

планлы күчмә тикшерү (ревизия) программасын раслау;

контрольлек объектына планлы күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү турында хәбәр итү;

планлы күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү;

планлы күчмә тикшерү (ревизия) нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

5.2.3.Контрольлек объектына планлы күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү өчен контрольлек чарасына җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү, Министр боерыгын рәсмиләштерү, тикшерү программасын раслау, тикшерү үткәрү турында контрольлек объектына хәбәр итү бу Регламентның 5.1.4-5.1.7 пунктчаларында күздә тотылган тәртиптә хәл ителә.

Тикшерү (ревизия) үткәрү өчен экспертлар, эксперт оешмалары катнашында контрольлек чараларын үткәрү таләп тиелгән очракта үзенә карата тикшерү үткәрелә торган контрольлек объекты белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелә торган контрольлек объекты белән

аффилирлы затлар булып тормаган экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре җәлеп ителә.

5.2.4. Контрольлек чарасы өчен җаваплы вазыйфаи затлар, экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре контрольлек объектына килгәннән соң, тикшерүне:

– хезмәт таныклыкларын күрсәтүдән;

– контрольлек объекты җитәкчесен планлы күчмә тикшерү билгеләү турында Министр боерыгын күрсәтүдән;

– контрольлек объекты җитәкчесен, хосусый эшмәкәрне һәм физик затны күчмә тикшерү үткәрүче затларның вәкаләтләре, шулай ук планлы күчмә тикшерү үткәрү максатлары, бурычлары, нигезләре белән, контрольлек чараларының төрләре һәм күләмнәре, планлы күчмә тикшерүгә җәлеп ителә торган экспертлар составы, эксперт оешмалары вәкилләре, үткәрү сроклары һәм шартлары белән мәҗбүри төстә таныштырудан башлый.

Тикшерү (ревизия) төркеменә контрольлек объекты территориясенә яки бүлмәсенә керүгә комачаулык тудырылганда, тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесе тарафыннан бу регламентка №5 кушымта нигезендәге форма буенча акт төзелә.

Күчмә тикшерү (ревизия) барышында контрольлек объектының документларда теркәлгән һәм факттагы эшчәнлеген өйрәнү буенча контрольлек гамәлләре башкарыла. Документларны өйрәнү буенча контрольлек гамәлләре, финанс, бухгалтерия, хисап документларына, сатып алуларны планлаштыру һәм хәл итү документларына һәм башка контрольлек объекты документларына карата үткәрелә, шулай ук контрольлек объектының вазыйфаи, матди яктан җаваплы затлары һәм башка затларының телдән һәм язмача аңлатмаларыннан, белешмәләре һәм мәгълүматларыннан чыгып һәм башка контрольлек чараларын кылу нигезендә алынган мәгълүматны анализлау һәм бәяләү юлы белән үткәрелә. Фактларны өйрәнү буенча контрольлек чаралары тикшерү, инвентарьлаштыру, күзәтү, яңадан исәпләү, экспертиза ясау, контроль үлчәүләр алу һәм башка контрольлек гамәлләре нигезендә хәл ителә.

Ялганлау, урлау, вазыйфасыннан үзенә файда алуда куллану ачыкланган очракта һәм мондый хокукка каршы гамәлләргә киртә кую зарурилыгы булганда, тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесе, Россия Федерациясе законында билгеләнгән чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле документлар һәм материалларны ала, бу Регламентка №6 кушымта нигезендәге форма буенча алу актын төзи, шулай ук тиешле эшләр буенча алынган документлар күчермәләрен яки исемлеген булдыра. Җинаять составы билгеләренә күрсәтә торган мәгълүматлар ачыкланган очракта тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесе кассаны, касса һәм хезмәт бүлмәләрен, склад һәм архивларны мөһер куеп яба.

Министр күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү срогын, тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесенең нигезле мөрәҗәгате буенча, күп дигәндә ун эш көненә озайта ала.

Күчмә тикшерү (ревизия) срогын озайту турында боерык басылып чыкканнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча боерык күчермәсе, бу Регламентта билгеләнгән тәртиптә, контрольлек объекты вәкиленә җибәрелә (тапшырыла).

Министр тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесенең нигезле мөрәҗәгате буенча билгеләргә мөмкин.

- тикшеренү үткәрүне;
- каршы тикшерү үткәрүне.

Планлы күчмә тикшерүләр (ревизия) кысаларында үткәрелә торган тикшеренүләр һәм (яки) каршы тикшерүләр бу Регламентның 5.1.4-5.1.7, 5.3.4-5.3.7 пунктчаларында күздә тотылган тәртиптә хәл ителә.

Планлы күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү Министр тарафыннан тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесенең нигезле мөрәҗәгате буенча туктатып торылырга мөмкин:

- каршы тикшерү һәм (яки) тикшеренү үткәрү чорына;

- контрольлек объектының бухгалтерия (бюджет учеты булмаганда яки канәгатьләнерлек дәрәҗәдә булмаганда – күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү өчен кирәкле документларны контрольлек объекты тарафыннан торгызу, шулай ук учет һәм хисап документларын тиешле хәлгә китерү чорына;

- экспертизалар оештыру һәм үткәрү чорына;

- компетентлы органнарга җибәрелгән запросларны үтәү чорына;

- контрольлек объекты тарафыннан мәгълүмат, документлар һәм материаллар тапшырылмау һәм яки кирәкле мәгълүмат, документлар һәм материалларның тулысынча тапшырылмау һәм (яки) контрольлек чарасын үткәрүгә комачаулау һәм (яки) контрольлек чарасын үткәрүдән читләшү-качу очрагында;

- контрольлек объектының урнашу урыны буенча булдырылган милеккә һәм (яки) документларга тикшеренү үткәрү зарурилыгы очрагында.

Күчмә тикшерүне (ревизия) туктатып тору вакытында аның срогы өзелә. Тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесе күчмә тикшерү (ревизия) үткәрүне туктатып тору турында Министр тарафыннан карар кабул итү көненнән соң өч көн эчендә (эш көннәрендә исәпләнелә):

- контрольлек объектына тикшерү үткәрүне туктатып тору һәм туктатып тору сәбәпләре турында язмача хәбәр итә;

- күчмә тикшерү (ревизия) үткәрүдә комачаулыкларны юкка чыгару буенча Россия Федерациясе законында күздә тотылган һәм күчмә тикшерү (ревизия) үткәрүне яңартуга ярдәм итәрдәй чаралар күрергә мөмкин.

Министр күчмә тикшеренүне туктатып тору сәбәпләре юкка чыгару турында мәгълүматлар алынганнан соң өч көн эчендә (эш көннәрендә исәпләнелә) күчмә тикшерү (ревизия) үткәрүне яңартып җибәрү турында карар кабул итә.

Тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесе бу пунктта күрсәтелгәнчә, Министр тарафыннан карар кабул итү көненнән соң өч көн эчендә (эш көннәрендә исәпләнелә) контрольлек объектына күчмә тикшерү (ревизия) үткәрүне яңарту турында хәбәр итә.

Башкару срогы: контрольлек объектына планлы күчмә тикшерү үткәрүнең гомуми срогы – күп дигәндә утыз эш көне.

Гамәл нәтиҗәсе: тикшерү программасы нигезендә планлы күчмә тикшерү үткәрү.

5.2.5. Планлы күчмә тикшерү (ревизия) нәтиҗәләре буенча тикшерүне үткәрүче вазыйфаи зат бу Регламентка №7 кушымта нигезендәге форма буенча акт рәсмиләштерә.

Планлы күчмә тикшерү (ревизия) акты проекты тикшерү үткәрү тәмамлануга ике эш көне кала Министр (беренче урынбасары) министр урынбасары) тарафыннан карап тикшерелергә тиеш.

Актка, планлы күчмә тикшерү үткәрү срогының ахыргы көненнән дә соңга калмыйча тикшерүне үткәрүче вазыйфаи зат кул куя.

Планлы күчмә тикшерү акты ике нөсхәдә төзелә, шуларның берсе, имза салынганнан соң өч көн эчендә (эш көннәрендә исәпләнелә) контрольлек объекты вәкиленә тапшырыла яки почта аша заказлы хат белән тапшыру турында уведомление белән) яисә адресат тарафыннан алыну датасын дәлилләүче башка ысул белән җибәрелә. Планлы күчмә тикшерү актының икенче нөсхәсе делога тегеп куела.

Күчмә тикшерү (ревизия) актына (каршы тикшерү актыннан һәм тикшеренү үткәрү нәтиҗәләре буенча әзерләнгән бәяләмәдән тыш) контрольлек чаралары үткәрү барышында алынган документлар, экспертизалар (тикшеренүләр) нәтиҗәләре, фото-, видео- һәм аудио материаллар кушып бирелә.

Акт һәм күчмә тикшерүнең (ревизия) башка материаллары Министр яки аның кушуы буенча Министрның беренче урынбасары, Министр урынбасарлары тарафыннан актка кул куелганнан соң унбиш көн эчендә (эш көннәрендә исәпләнелә) карап тикшерелергә тиеш.

Министр актны һәм күчмә тикшерү (ревизия) үткәрүнең башка материалларын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул итә:

а) мәҗбүриләү чараларын куллану турында;

б) мәҗбүриләү чараларын куллануга нигезләрнең булмавы турында;

в) контрольлек объекты, күчмә тикшерү (ревизия) нәтиҗәләре буенча ясалган йомгакларга йогынты ясардай, тикшерелә торган чорга кагылышлы өстәмә мәгълүмат, документлар һәм материаллар белән, язмача каршы килүләр тапшырганда, планлы күчмә тикшерү (ревизия) билгеләү турында.

Россия Федерациясе бюджет законын бозулар ачыкланган очракта Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15.1, 15.14-15.15.16 статьяларында күздә тотылган хокук бозулар составлары буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзи.

Башка дәүләт органы (вазыйфаи зат) компетенциясенә кергән бозу билгеләре турында дәлилләүче хәлләр һәм фактлар ачыкланган очракта, мондый материаллар Россия Федерациясе законы нигезендә билгеләнгән тәртиптә карап тикшерүгә җибәрелә.

Министрлык контрольлек объектына танытмалар һәм (яки) күрсәтмәләр җибәрә. Китерелгән зыянны каплау турында танытманы һәм (яки) күрсәтмәне үтәмәү очрагында Министрлык мондый танытманы һәм (яки) күрсәтмәне үтмәгән затка Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылык чаралары күрә.

Россия Федерациясе бюджет законын һәм бюджетта хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы башка норматив-хокукый актларны бозу нигезендә Татарстан Республикасына китерелгән зыянны каплау турында күрсәтмәне үтәмәү очрагында Министрлык мондый бозуга юл куйган контрольлек объекты, вазыйфаи затлар тарафыннан Татарстан Республикасына китерелгән зыянны каплау турында судка дәгъва гаризасы җибәрә һәм судта әлеге дәгъва буенча Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен яклый.

Башкару срогы:

актны төзү һәм имзалау – планлы күчмә тикшерү үткәрү срогының соңгы көненнән дә соңга калмыйча;

контрольлек объектына акт тапшыру (җибәрү) – имза салынганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча;

планлы күчмә тикшерү материалларын карап тикшерү һәм Министр тарафыннан карар кабул итү – актка кул куелганнан соң унбиш эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәл нәтиҗәсе:

планлы күчмә тикшерү актының ике нөсхәсе, шуның берсе контрольлек объекты исеменә җибәрелә, икенчесе – делога теген куела;

актны һәм планлы күчмә тикшерү буенча башка материалларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министр тарафыннан кабул ителгән карар.

5.2.6. Контрольлек объекты планлы күчмә тикшерү (ревизия) актына мондый акт алынганнан соң биш эш көне эчендә, язмача рәвештә каршы килүләрне тапшыруга хокуклы. Контрольлек объектының язмача каршы килүләре планлы күчмә тикшерү (ревизия) материаллары янына куела.

5.2.7. "Планлы күчмә тикшерү үткәрү" (ревизия) административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе электрон рәвештә Министрлыкның рәсми сайтында теркәлә.

5.3. "Тикшеренү үткәрү" административ процедурасы

5.3.1. "Тикшеренү үткәрү" административ процедурасын башлауга нигез булып тиешле контрольлек объектына тикшеренү үткәрү турында Министрның карары тора.

5.3.2. "Тикшеренү үткәрү" административ процедурасы административ гамәлләрнең түбәндәге тәртибе нигезендә хәл ителә:

тикшеренү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затны билгеләү;

тикшеренүне үткәрү турында боерыкны рәсмиләштерү;

тикшеренү программасын раслау;

тикшеренү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

5.3.3. Контрольлек объектына тикшеренү үткәрү өчен контрольлек чарасына җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү, Министр боерыгын рәсмиләштерү, тикшеренү программасын раслау, тикшеренү үткәрү турында контрольлек объектына хәбәр итү бу Регламентның 5.1.4-5.1.7 пунктчаларында күздә тотылган тәртиптә хәл ителә.

5.3.4. Контрольлек чарасы өчен җаваплы вазыйфаи затлар, экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре тикшеренү объектына килгәннән соң, тикшерүне:

– хезмәт таныклыкларын күрсәтүдән;

– тикшеренү объекты җитәкчесен тикшеренүне билгеләү турында Министр боерыгын күрсәтүдән башлый.

Тикшерү (ревизия) төркеменә контрольлек объекты территориясенә яки бүлмәсенә керүгә комачаулык тудырылганда, тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесе тарафыннан бу регламентка №5 кушымта нигезендәге форма буенча акт төзелә.

Күчмә тикшеренү вакытында Министр боерыгы белән билгеләнгән контрольлек объекты эшчәнлеге өлкәсе анализлана һәм бәяләнә. Тикшеренү үткәрелгәндә, фото-, видео- һәм аудиотехникадан, шулай ук башка техника

төрләреннән һәм приборлардан, шул исәптән үлчәү приборларыннан файдаланып, тикшеренүләр һәм экспертизалар үткәрелергә мөмкин.

Башкару срогы: контрольлек объектына тикшеренү үткәрү срогы – күп дигәндә утыз эш көне.

Гамәл нәтиҗәсе: тикшерү программасы нигезендә тикшеренү үткәрү.

5.3.5. Тикшеренү нәтиҗәләре буенча вазыйфаи зат бәяләмә рәсмиләштерә, бәяләмә түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) тикшеренү үткәрүгә нигез;

б) тикшеренү максатлары һәм бурычлары;

в) файдаланган мәгълүматка характеристика;

г) үткәрелгән тикшеренү буенча алынган нәтиҗәләр.

Бәяләмә ике нөсхәдә төзелә һәм вазыйфаи зат тарафыннан тикшеренү үткәрү срогының ахыргы көненнән дә соңга калмыйча имзалана. Бәяләмәнең бер нөсхәсе, имза салынганнан соң өч көн эчендә (эш көннәрендә исәпләнелә) бу Регламент нигезендә контрольлек объекты вәкиленә тапшырыла. Бәяләмәнең икенче нөсхәсе делога тегеп куела.

Бәяләмә һәм тикшеренүнең башка материаллары Министр яки аның кушуы буенча Министрның беренче урынбасары, Министр урынбасарлары тарафыннан, бәяләмәгә кул куелганнан соң ун көн эчендә (эш көннәрендә исәпләнелә) карап тикшерелергә тиеш. Министр күчмә тикшерү (ревизия) билгеләргә мөмкин.

Башкару срогы:

бәяләмәне төзү һәм имзалау – тикшеренү үткәрү срогының соңгы көненнән дә соңга калмыйча;

контрольлек объектына бәяләмә тапшыру (җибәрү) – имза салынганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча;

тикшеренү материалларын карап тикшерү һәм Министр тарафыннан карар кабул итү – бәяләмәгә кул куелганнан соң унбиш эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәл нәтиҗәсе:

тикшеренү бәяләмәсенең ике нөсхәсе, шуның берсе контрольлек объекты исеменә җибәрелә, икенчесе – делога тегеп куела;

бәяләмәне һәм тикшеренү үткәрү буенча башка материалларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министр тарафыннан кабул ителгән карар.

5.3.7. Контрольлек объектлары тикшеренү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән бәяләмәгә (камераль һәм күчмә тикшерүләр, ревизияләр кысаларында үткәрелә торган тикшеренүдән тыш) мондый бәяләмә алынганнан соң биш эш көне эчендә, язмача рәвештә каршы килүләрне тапшыруга хокуклы. Контрольлек объектының язмача каршы килүләре тикшеренү материаллары янына куела.

5.3.8. “Тикшеренү үткәрү” административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе электрон рәвештә Министрлыкның рәсми сайтында теркәлә.

5.4. “Планнан тыш камераль тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.4.1. “Планнан тыш камераль тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлауга нигез булып бу Регламентның 2.4.2 пунктчасында күрсәтелгән очраклар тора.

5.4.2. Планнан тыш камераль тикшерү бу Регламентның 5.1.2 пунктчасы нигезендә, Министрлыкның урнашу урыны буенча үткәрелә.

5.4.3. “Планнан тыш камераль тикшерү үткәрү” административ процедурасы административ гамәлләрнең түбәндәге тәртибе нигезендә хәл ителә:

планнан тыш камераль тикшерү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затны билгеләү;

планнан тыш камераль тикшерү үткәрү турында боерыкны рәсмиләштерү;

планнан тыш камераль тикшерү үткәрү программасын раслау;

планнан тыш камераль тикшерү үткәрү турында контрольлек объектына хәбәр итү;

планнан тыш камераль тикшерү үткәрү;

планнан тыш камераль тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

5.4.4. Министр бу регламентның 2.4.2 пунктчасында күрсәтелгән планнан тыш камераль тикшерү үткәрүгә нигезләр килеп чыкканда, Бүлек начальнигына планнан тыш камераль тикшерү оештыру һәм үткәрү турында поручение бирә. Бүлек начальнигы контрольлек объектына планнан тыш камераль тикшерү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затларны билгели.

Башкару срогы: планнан тыш камераль тикшерү үткәрүгә нигезләр килеп чыкканнан соң бер эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: планнан тыш камераль тикшерү үткәрүгә җаваплы итеп билгеләнгән вазыйфаи затлар.

5.4.5. Планнан тыш камераль тикшерү үткәрү турында боерыкны рәсмиләштерү, тикшерү программасын раслау, контрольлек объектына тикшерү үткәрү турында хәбәр итү, планнан тыш камераль тикшерү үткәрү (запрос җибәрү, контрольлек объекты турында тапшырылган мәгълүматны һәм документларны карап тикшерү һәм өйрәнү, шулай ук планнан тыш камераль тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү бу Регламентның 5.1.5-5.1.12 пунктчаларында билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

Планнан тыш камераль тикшерүләр кысаларында тикшеренүләр һәм (яки) каршы тикшерүләр бу Регламентның 5.1.4-5.1.7, 5.3.4-5.3.7 пунктчаларында күздә тотылган тәртиптә хәл ителә.

5.4.6. “Планнан тыш камераль тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе электрон рәвештә Министрлыкның рәсми сайтында теркәлә.

5.5. “Планлы күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү” административ процедурасы

5.5.1. “Планлы күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү” административ процедураны башлауга нигез булып бу Регламентның 2.4.2 пунктчасында күздә тотылган очраклар тора.

5.5.2. “Планлы күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү” административ процедурасы бу Регламентның 5.2.2 пунктчасында күрсәтелгән административ гамәлләр нигезендә хәл ителә.

5.5.3. Планлы күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү буенча контрольлек чарасы өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү, боерык рәсмиләштерү, программаны раслау, планнан тыш күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү турында контрольлек объектына хәбәр итү бу Регламентның 5.1.4-5.1.7 пунктчалары нигезендә хәл ителә.

5.5.4. Планлы күчмә тикшерү (ревизия) бу Регламентның 5.2.4. пунктчасында билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

5.5. Тикшерү актын төзү һәм планнан тыш күчмә тикшерү (ревизия) нәтиҗәләрен рәсмиләштерү бу Регламентның 5.2.5, 5.2.6 пунктчалары нигезендә хәл ителә.

5.5.6. “Планлы күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү” административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе электрон рәвештә Министрлыкның рәсми сайтында теркәлә.

## 6. Дәүләт вазыйфасын үтәүгә контрольлек итү тәртибе һәм формалары

6.1. Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан бу Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт вазыйфасын үтәүгә карата таләпләрне билгеләүче башка норматив-хокукый актларны үтәүгә, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүгә агымдагы контрольлекне хәл кылу тәртибе

6.1.1. Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан бу Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт вазыйфасын үтәүгә карата таләпләрне билгеләүче башка норматив-хокукый актларны үтәүгә, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүгә контрольлек Министр тарафыннан оештырыла.

6.1.2. Министр, министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, тикшерү (ревизия) төркеме тарафыннан бу Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт вазыйфасын үтәүгә карата таләпләрне билгеләүче башка норматив-хокукый актларны үтәүгә, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүгә агымдагы контрольлекне хәл итә.

6.1.3. Контрольлек чаралары барышында тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесе көн саен, контрольлек чарасы нәтиҗәләре буенча карар кабул иткәнче, контрольлек чарасын үткәрүгә карап, төркем эшенә контрольлек итә, контрольлек чарасын сыйфатлы һәм билгеләнгән срокта үткәрүгә җавап бирә.

6.2. Планлы һәм планнан тыш тикшерүләрнең тулылыгын һәм дәүләт вазыйфасын үтәүнең сыйфатын хәл итү тәртибе һәм вакыт аралыклары

6.2.1. Бүлекләр тарафыннан дәүләт вазыйфасын үтәүнең сыйфаты һәм тулылыгына контрольлек дәүләт вазыйфасын башкаруда турыдан-туры катнашучы Бүлекләрнең планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрү, вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләрне карап тикшерү һәм дәүләт вазыйфасын хәл иткәндә тикшерелә торган затларның хокукларын бозуларны юкка чыгару юлы белән хәл ителә.

6.2.2. Бүлекләр тарафыннан дәүләт вазыйфасын үтәүнең тулылыгы һәм сыйфатына планлы тикшерүләр дәүләт вазыйфасын үтәүгә компетентлы Министр урынбасары тарафыннан Министрның еллык эш планына кертелгән чаралар нигезендә үткәрелә.

6.2.3. Дәүләт вазыйфасын башкаруда турыдан-туры катнашучы Бүлекләрнең планнан тыш тикшерүләре, дәүләт вазыйфасын үтәү барышында кабул ителгән яки хәл ителгән министрлыкның вазыйфаи затларының карарларына яки гамәлләренә (гамәл кылмау) кызыксынулы затларның шикаятьләре нигезендә, Министр тарафыннан билгеләнә.

6.2.4. Бүлекләр тарафыннан дәүләт вазыйфасын үтәүнең тулылыгы һәм сыйфатына планлы тикшерүләр үткәрүнең тәртибе һәм вакыт аралыклары Министрлык тарафыннан билгеләнә.

Тикшерү вакытында дәүләт вазыйфасын үтәүгә бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки дәүләт вазыйфасын үтәүгә бәйле кайбер мәсьәләләр (тематик тикшерүләр) карап тикшерелергә мөмкин.

6.3. Дәүләт вазыйфасын үтәү барышында кабул ителгән карарлары һәм кылынган гамәлләре (гамәл кылмау) өчен Министрлыкның вазыйфаи затларының җаваплылыгы

Бу Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт вазыйфасын үтәүгә карата таләпләрне билгеләүче башка норматив-хокукый актларны бозулар ачыкланган очракта, Министрлыкның вазыйфаи затлары, Россия Федерациясе законы нигезендә, дәүләт вазыйфасын үтәү процессында кабул ителгән карарлары һәм кылынган гамәлләре (гамәл кылмау) өчен җавап бирә.

6.4. Дәүләт вазыйфасын үтәүгә контрольлек, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан, тәртибенә һәм формаларына карата таләпләр

6.4.1. Гражданнар, аларның берләшмәләре, оешмалары ягыннан дәүләт вазыйфасын үтәүгә контрольлек итү, дәүләт сере яки закон нигезендә саклана торган башка төрле серләрдән торган мәгълүматлардан тыш, “дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат белән таныштыруны тәэмин итү хакында” 9 февраль, 2009 ел, №8 ФЗ Федераль закон нигезендә билгеләнгән күләмдә, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла торган дәүләт вазыйфасын хәл итү нәтиҗәләре турында мәгълүмат алу юлы белән хәл ителә.

6.4.2. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары Министрлыкка дәүләт вазыйфасын үтәү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр, шулай ук вазыйфаи затларның бу Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт вазыйфасын үтәүгә карата таләпләрне билгеләүче башка норматив-хокукый актларны бозулары турында хәбәр белән гариза һәм шикаятьләр җибәрүгә хокуклы.

## 7. Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

7.1. Кызыксынулы зат, яки аның законлы вәкиле (алга таба – мөрәҗәгать итүче), буйсыну тәртибендә, югарыгы вазыйфаи затка Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының дәүләт вазыйфасын үтәү барышында кабул иткән карарларына һәм кылган гамәлләренә (гамәл кылмау) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә хокуклы.

7.2. Мөрәҗәгать итүче кәгазьдә яки электрон рәвештә почта аша яисә “Интернет мәгълүмат” телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлык сайты (http://www.minfin.tatar.ru) аша шикаять җибәрүгә, шулай ук Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать итеп шикаять тапшыруга хокуклы. Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять министрга (Министрның беренче урынбасары, контрольлек чараларын оештыруга җаваплы Министр урынбасары) җибәрелергә мөмкин.

7.3. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмау) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү предметы булып дәүләт вазыйфасын үтәү барышында кабул ителгән яки кылынган Министрлыкның вазыйфаи затлары карарлары яки гамәлләре (гамәл кылмау) тора.

7.4. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процедурасын башлауга нигез булып Министрлыкка мөрәҗәгать итүчедән шикаять алыну тора.

7.5. Шикаять тапшыру Министрлыкның шикаять белдерелгән карарын үтәүне яки шикаять белдерелгән гамәлнең вазыйфаи зат тарафыннан кылынуын туктатмый, Министрлыкның шикаять белдерелгән карарын үтәү яки Министрлыкның вазыйфаи заты гамәлләре Министр тарафыннан туктатылмаган очракта.

Министрлыкның карарына яки Министрлыкның вазыйфаи заты гамәленә шикаять белдерелгән очракта мөрәҗәгать итүче үтенечнамәсе буенча Министрлыкның шикаять белдерелгән карарын үтәү яки шикаять белдерелгән вазыйфаи зат гамәле, әлеге карар яки гамәлнең Россия Федерациясе законына туры килмәвенә җитәрлек дәрәҗәдә нигезләр булган очракта, Министр тарафыннан туктатылырга мөмкин.

Үтенечнамә буенча кабул ителгән карар турында, кабул ителгәннән соң өч көн эчендә мөрәҗәгать итүчегә язмача рәвештә җиткерелә.

7.6. Шикаятьтә булырга тиеш:

а) йә мөрәҗәгать итүче шикаять юллаган дәүләт органы атамасы, яки тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме яисә тиешле затның вазыйфасы;

б) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), җавап җибәрелергә тиешле почта адресы, башка адреска җибәрү турында уведомление;

в) шикаятьнең асылы;

г) шәхсән имзасы һәм дата.

Кирәк булган очракта, мөрәҗәгать итүче үз дәлилләрен раслап шикаятькә документлар һәм материаллар яки аларның күчермәләрен кушып бирүгә хокуклы.

7.7. Шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүче өстәмә документлар һәм материаллар тапшыруга, шулай ук шикаятьне нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле мәгълүмат һәм документлар соратып алуга хокуклы.

7.8. Министрлыкка яки югарыгы вазыйфаи затка алынган шикаять үзләренең компетенциясе нигезендә, мәҗбүри тәстә карап тикшерелергә итеш. Судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне карап тикшерүдән баш тартуга яки карап тикшерүне туктатып торуга нигезләр күздә тотылмаган.

7.9. Аерым шикаятьләрне карап тикшерү тәртибе

7.9.1. Язмача шикаятьтә шикаятьне җибәргән гражданинның фамилиясе яки җавап җибәрү өчен кирәкле почта адресы күрсәтелмәгәндә шикаятькә җавап бирелми.

Шикаятьтә әзерләнелә, кылына торган яки кылынган хокукка каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында мәгълүматлар урын алганда, шикаять тиешле компетенциядәге дәүләт органына җибәрелә.

7.9. Министрлык яки Министрлыкның вазыйфаи заты  вазыйфаи затка, шулай ук аның гаиләсе әгъзаларына карата сүгенү яки мыскыллау сүзләре, тормышы, сәламәтлеге һәм милкенә янаулар белән язмача шикаять алганда, шикаятьне җавапсыз калдыра һәм шикаятьне җибәргән гражданинга үз хокукыннан фәкать тиешенчә файдалану зарурилыгы турында хәбәр итә ала.

7.9.3. Язмача шикаятьне, почеркы начар булу сәбәпле, укып булмаган очракта шикаятькә җавап бирелми, һәм ул тиешле компетенциядәге дәүләт органына, җирле

үзидарә органына яки вазыйфаи затка карап тикшерүгә җибәрелми, бу хакта, шикаятьне теркәүгә алганнан соң җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән гражданинга хәбәр ителә (фамилиясен һәм почта адресын укып булганда).

7.9.4. Гражданинның язмача шикаятендә элек җибәрелгән шикаятьләренә бәйле рәвештә язмача җаваплар инде берничә тапкыр бирелгән сорау урын алып, шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр һәм хәлләр китерелмәс, министр яки вазыйфаи зат яки вәкаләтле зат чираттагы шикаятьнең нигезсезлеге һәм әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән хат язышуны туктату турында карар кабул итүгә хокуклы (әлеге шикаять элегрәк тә Министрлыкка җибәрелгән очракта). Әлеге карар турында шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә җиткерелә.

7.9.5. Шикаятьтә күтәрелгән сорауның асылына җавап бирү дәүләт сере яки федераль закон нигезендә сакланыла торган башка төрле сер булып торган мәгълүматларны таратуга китергән очракта, шикаятьне җибәргән гражданинга, бу мәгълүматларны таратырга ярамау сәбәпле, күтәрелгән сорауның асылына җавап биреп булмау турында хәбәр ителә.

7.9.6. Шикаятьтә күтәрелгән сорауларның асылына җавап биреп булмау сәбәпләре соңыннан юкка чыгарылган очракта гражданин Министрлыкка яки тиешле вазыйфаи затка шикаятьне янә җибәрүгә хокуклы.

7.9.7. Суд карарына шикаять теркәүгә алынганнан соң җиде көн эчендә, әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, шикаять җибәрелгән гражданинга кире кайтарып бирелә.

7.10. Шикаятьне карап тикшерү срогы теркәлгәннән соң утыз календарь көненнән дә артмаска тиеш.

Чыгарма очракларда, шулай ук шикаятьне карап тикшерү максатында кирәкле документлар һәм материаллар алу өчен башка дәүләт органнарына, башка вазыйфаи затларга запрос җибәрү очрагында, Министр яки вәкаләтле вазыйфаи зат шикаятьне карап тикшерү срогын озайтуга хокуклы, әмма күп дигәндә утыз календарь көненә генә (бу хакта, срокны озайту сәбәпләрен күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә җиткерелә).

7.11. Министр шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Министрлыкның карарын юкка чыгару (аның вазыйфаи затларының) гамәлләренең (гамәл кылмау) законсыз дип тану;

б) шикаятьне канәгатьләндерү;

в) шикаятьне канәгатьләндермичә калдыру.

Әлеге карар өч эш көне эчендә Министр боерыгы белән рәсмиләштерелә.

7.12. Мөрәҗәгать итүчегә язмача рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында җавап (шикаятьне канәгатьләндерү яки шикаятьне канәгатьләндермичә калдыру очрагында) яисә озату хаты (шикаятьне тулысынча канәгатьләндерү очрагында) җибәрелә.

7.13. Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең административ регламентына (06.06.2014 ел, №21-72-21) №1 кушымта**

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты территориаль бүлекләренең районара контрольлек-ревизия бүлекләре исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Әлмәт районы һәм Әлмәт ш. территориаль бүлеге
Адресы: 423461, Әлмәт ш., Ленин ур., 113 “а” й.
тел.: (8553) 33-12-96
электрон почта адресы: almat.kazna@tatar.ru

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Буа районы территориаль бүлеге
адресы: 422433, Буа ш., Вахитов ур., 71 “а” й.
тел.: (84374) 3-53-75
электрон почта адресы: buinsk.kazna@tatar.ru


3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Зеленодол районы һәм Зеленодол ш. территориаль бүлеге
адресы: 422540, Зеленодол ш., Ленин ур., 38 й.
тел.: (84371) 5-51-41
электрон почта адресы: zelenodol.kazna@tatar.ru

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Чаллы ш. территориаль бүлеге
адресы: 423805, Чаллы ш., Хәсән Туфан пр., 23 й.
тел.: (8552) 58-51-82
электрон почта адресы: chally.kazna@tatar.ru

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Чистай районы һәм Чистай ш. территориаль бүлеге
адресы: 422980, Чистай ш., К.Маркс ур., 19 “б” й.
тел.: (84342) 5-04-15
электрон почта адресы: chistay.kazna@tatar.ru


**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан**
**финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү буенча**
**дәүләт хезмәте күрсәтүнең**
**административ регламентына (06.06.2014 № 21-72-21) №2 кушымта**

Закон нигезендә билгеләнгән очракларда, бюджетта хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә эчке дәүләт финанс контрольлеге һәм җирле бюджетларны үтәүгә контрольлек вәкаләтләрен хәл итүдә дәүләт вазыйфасын үтәүнең блок-схемасы



**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан**
**финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү буенча**
**дәүләт хезмәте күрсәтүнең**
**административ регламентына (06.06.2014 № 21-72-21) №2 а кушымта**

Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга карата эчке дәүләт финанс контрольлегe буенча вәкаләтләрне хәл итүдә дәүләт вазыйфасын үтәүнең блок-схемасы



**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең**

**административ регламентына (06.06.2014 № 21-72-21) №3 кушымта**

______________________________________________________________

(эчке дәүләт финанс контрольлеге органы атамасы)

БОЕРЫК

______________________________________ тикшерү (ревизии, тикшеренү)
үткәрү турында (планлы/планнан тыш, камераль/күчмә)

"____" ____________________ ел № _______

1. Тикшерү үткәрүгә нигез ______________________________________________

______________________________________________________________

2. карата тикшерү үткәрүегезне сорыйм ______________________________________________

______________________________________________________________

(учреждениесе атамасы)

3. Бу тикшерүнең түбәндәге максатта үткәрелүен билгеләргә: ______________________________________________

______________________________________________________________

4. Тикшерү чоры: ______________________________________________

5. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле затлар итеп билгеләргә: ______________________

______________________________________________________________

(тикшерү үткәрүгә вәкаләтле затның (затлар) фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы)

6. Түбәндәге затларны экспертлар, эксперт оешмалары сыйфатында тикшерү үткәрүгә җәлеп итәргә: ______________________________________________

______________________________________________________________

(тикшерү үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларның фамилиясе, исеме, атасының исеме вазыйфалар һәм (яки)эксперт оешмасы атамасы, аккредитацияләү турында таныклык реквизитларын һәм аккредитацияләү турында таныклык биргән аккредитацияләү органы атамасы)

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(эчке дәүләт контрольлеге органы җитәкчесе вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары ) ______________________
(мөхер белән расланган имза)

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең административ регламентына (**06.06.2014 № 21-72-21) №4 кушымта

Камераль тикшерү үткәрелгәндә контрольлек объекты тарафыннан мәгълүмат тапшырмау АКТы

"___" ____________________ 20____ ел
(актны төзү датасы)

__________________________________
(актны төзү урыны)

Нигезендә:
______________________________________________________________________________
______________________________________________
______________________________________________________________________________
(документ төре, тикшерүче дәүләт органы реквизитларын (номеры, дата), җитәкчесенең, җитәкче урынбасарының фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын, эчке дәүләт финанс контрольлеге органы атамасын күрсәтеп)

Камераль тикшерү үткәрелгәндә соралган түбәндәге документлар күрсәтелмәгән:
______________________________________________________________________________
______________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________
______________________________________________________________________________

Документларны тапшырмау
сәбәпләре:_________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________

Тикшерү үткәргән затларның имзалары:

Тикшерелә торган оешма вәкилләре затларының имзалары:

Тикшерү акты белән таныштым, акт күчермәсен, кушымталары белән, алдым:
________________________________________________________________

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан**
**финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү буенча**
**дәүләт хезмәте күрсәтүнең**

**административ регламентына (06.06.2014 № 21-72-21) №5 кушымта**

Контрольлек чарасы үткәрелгәндә җаваплы вазыйфаи затларга комачаулыклар тудыру фактлары турында
АКТ

__________________ "___" __________ 20__ ел
(торак пункт)

Түбәндәгеләр нигезендә
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
(Контрольлек чараларының эш планы пункты, планнан тыш контрольлек чарасы үткәрүгә башка нигезләр)

объектта ________________________________________________________________
(контрольлек чарасы объекты атамасы)

Контрольлек чарасы үткәрелә _____________________________________________
__________________________________________________________________________
(контрольлек чарасы атамасы)
Вазыйфаи затлар тарафыннан
__________________________________________________________________________
(контрольлек чарасы объекты атамасы,
__________________________________________________________________________
Затларның вазыйфасы, инициаллары һәм фамилияләре)
Министрлык хезмәткәрләренә комачаулыклар тудырылды
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
(хезмәткәрләрнең вазыйфасы, инициаллары һәм фамилияләре )
әлеге контрольлек чараларын үткәрүдә, болар - ______________________________
__________________________________________________________________________
(чара үткәрү өчен комачаулыклар тудыруның конкрет фактлары – Министрлык хезмәткәрләрен объектка кертмәү, мәгълүмат тапшырмау)

Бу Акт ике нөсхәдә төзелде, шуның берсе танышу өчен тапшырылды (яки җибәрелде)
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
(тикшерелә торган объектның вазыйфаи заты, фамилиясе һәм инициаллары)

Контрольлек чарасы җитәкчесе
_____________ _________________ ___________________________
(вазыйфасы) (шәхсән имзасы) (инициаллары, фамилиясе)

Актның бер нөсхәсен алды
_____________ _________________ ___________________________
(вазыйфасы) (шәхсән имзасы) (инициаллары, фамилиясе)

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан**
**финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү буенча**
**дәүләт хезмәте күрсәтүнең**

**административ регламентына (06.06.2014 № 21-72-21) №6 кушымта**

Контрольлек чарасы объектының документлары алу турында
АКТ

_________________ "__" __________ 20__ ел
(торак пункт)

нигезендә ______________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________
(Контрольлек чараларының эш планы пункты, планнан тыш контрольлек чарасы үткәрүгә башка нигезләр)
объектта__________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________
(контрольлек чарасы объекты атамасы)
Контрольлек чарасы үткәрелә_____________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________
(контрольлек чарасы атамасы)
нигезендә_______________________________________________________________________________
("Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет контрольлеге өлкәсендә вәкаләтләрне хәл итү тәртибен раслау турында" 07.02.2014 ел, №67 ТР МК карарының 49 пункты)

Тикшерү өчен түбәндәге документлар алынды:
1. ____________________________________________________________ ____ битле
2. ____________________________________________________________ ____ битле
3. ____________________________________________________________ ____ битле

Документларны алды вазыйфаи затларның күз алдында хәл ителде______________________________
__________________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________
(контрольлек чарасы объекты атамасы, затларның вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары )
__________________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________

Бу Акт ике нөсхәдә төзелде, шуның берсе танышу өчен тапшырылды (яки җибәрелде)
__________________________________________________________________________________________
(тикшерелә торган объектның вазыйфаи заты, фамилиясе һәм инициаллары)
__________________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________

Контрольлек чарасы җитәкчесе
_________________ _________________ _________________
(вазыйфасы) (шәхсән имзасы) (инициаллары,фамилиясе)

Актның бер нөсхәсен алды
_________________ _________________ _________________
(вазыйфасы (шәхсән имзасы) (инициаллары,фамилиясе)

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең**

**административ регламентына (06.06.2014 № 21-72-21) №7 кушымта**

ТИКШЕРҮ АКТЫ

"___" ____________________ 20___ел ________________________________
(актны төзү датасы) (актны төзү урыны)

нигезендә: ____________________________________________________________________________

(документ төре, тикшерүче дәүләт органы реквизитларын (номеры, дата), җитәкчесенең, җитәкче урынбасарының фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын, эчке дәүләт финанс контрольлеге органы атамасын күрсәтеп)

тикшерү үткәрелде______________________________________________________________

(планлы/планнан тыш, камераль/күчмә)

карата:

______________________________________________________________________________________

(учреждение атамасы)

Тикшерүне башлау датасы:______________
Тикшерүне төгәлләү датасы: ______________________

Учреждениенең тулы рәсми исеме___________________________________________________

Учреждениенең нинди документ нигезендә үз эшчәнлеген алып баруы___________________________________________________________________________

Гамәлгә куючылары

______________________________________________________________________________________

Эшчәнлекнең гамәлгә кую документларына туры килүе _________________________________

Учреждение реквизитлары

_____________________________________________________________________________

(юридик адресы, финанс-хуҗалык эше өчен җаваплы затлар; кредит оешмаларындагы барлык счетларының исемлеге һәм реквизитлары, шулай ук Федераль казначылык органнарындагы лицевой счетлары)

Финанс-хуҗалык эшчәнлеге тасвирламасы____________________________________________________________________

(касса һәм банк операцияләрен алып бару, төп средстволарны инвентарьлаштыру, матди кыйммәтләрне һәм төп средстволарны гамәлдән сызып ташлау, бухгалтерия учетын алып бару һәм хисап тотуның дөреслеген тәэмин итү, дебиторлык һәм кредиторлык бурычын анализлау, автоном һәм бюджет учреждениеләре тарафыннан дәүләт заказын үтәү һ.б.)

Тикшерү барышында бозулар ачыкланды

_____________________________________________________________________________

(бозулар характерын һәм норматив-хокукый актка сылтаманы күрсәтеп)

_____________________________________________________________________________

Тикшерүне үткәргән затлар имзалары :

Тикшерелә торган учреждение вәкилләре затларының имзалары:

Тикшерү акты белән таныштым, акт күчермәсен алдым: ________________________________